СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

15 октябрь, 1997ел.
ЧӘРШӘМБЕ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 116 (8128) | Бәясе билгеләнгәнчә

**Авылда көн бурычлары :шикәр чөгендере алуны тизләтү өчен (әлегә ул 60 процентта башкарылган) агрегатларның тәүлек әйләнәсенә эшләвен тәэмин итү,аны кабул итү пунктларына ташу темпын арттыру; якын көннәрдә туңга сөрүне төгәлләү,моның өчен хуҗалыкара ярдәм оештыру; бөртеккә кукуруз җыюга игътибарны арттыру**

## Олы йортта ни булса,

кечесендә дә шул ук, диләр бит. «Агропромбанк»ның «Лесная Поляна» ярдәмче хуҗалыгында да, җир мәйданы чагыштырмача аз булганга карап кына мәшәкатьләр әллә ни ким түгел. Бердән, эшче көчләр ташып тормаса, икенчедән, техника да санаулы гына. Шулай да механизаторларыбыз үз алларында торган бурычны намус белән башкарып чыктылар. Уракның төп авырлыгы Владимир Ильич Колесников белән Анатолий Геннадьевич Уницаев җилкәсендә булды. Бар булган ашлыкны «Нива» комбайннары белән алар суктырды. Дәүләткә ашлык сату заданиесен районда иң беренчеләрдән булып тутырганбыз икән, бу берьяктан аларның ашлыкны югалтуларсыз җыеп алу өчен зур тырышлык куюлары нәтиҗәсе дә. Уңган механизаторлар урак беткәч тә тик тормыйлар. Анатолий «Беларусь» тракторында төрле нарядлар үти, ә Владимир РКС - 6 комбайны белән «40 лет Победы» хуҗалыгында шикәр чөгендере казыта. Сүз уңаеннан, чөгендер комбайннарының икенчесе дә тик тормый - Сергей Иванович Семенов аның белән МСО ярдәмче хуҗалыгы кырларында эшли.

Дөрес, әле үзебездә дә эш бетеп җитмәгән. Шулардан иң мөһиме - туңга сөрү. Тракторларыбыз бик тузган булса да, механизаторларыбызның тырышлыгы бу эшнең дә зур өлешен уңайлы һәм кулай вакытта башкарып чыгарга мөмкинлек бирде. Владислав Еграшкинның ДТ - 75е көйле генә эшләде быел һәм туңга сөрелгән мәйданнарның зур өлеше аның исәбендә. Николай Николаев белән Николай Грушев та тузган тракторлары еш ватылса да, хәл кадәренчә тырыштылар. Хәрби хезмәтне Чечняда үткән егетебез Владимир Грушев әле тагын бер иске тракторны сафка бастырып килә һәм аңар да эш табылыр.

**В.МЕНЗЕЛЕЕВ,**
**агроном.**



Уракка төшәр алдыннан «ДОН - 1500» комбайннары парады уздырылган көнне төшерелгән иде бу рәсем. Чулпан кусты хуҗалыкларыннан җыелган комбайннар арасында «Игенче»некеләр бары тик уңай яктан гына бәяләнде ул чакта. Шулай булмыйча соң, хуҗалыктагы өч «ДОН» да бүгеннән кырга чыгардай иттереп әзерләнгән иде бит. Шул исәптән арада иң искесе булганы да. Монысы инде «ДОН»ның хуҗасы Әхәт Ибраһимовның техниканы яхшы белүе, әйбәтләп каравы, җаен гына белеп эшләтүе нәтиҗәсе дә булып тора. Комбайнның төрлесендә эшләп, бай тәҗрибә туплаган механизатор бер генә эшне дә «әйдә ярар»га башкарырга күнекмәгән. Шуңа күрә әле менә шушы иң иске «ДОН»ның иң нечкә, иң җитди урыннарын бер генә дә кузгатырга туры килгәне юк. Быелгы уракта да ватылусыз эшләде Ибраһимовларның комбайны (штурвалы ике бертуган Әхәт һәм Тәлгать кулында аның). Нигездә турыдан - туры урдырып суктыруда булды алар, шуңа алай да хуҗалыкта икенче нәтиҗә белән төгәлләделәр уракны. Әле үзләрендә эшне бетергәч күрше хуҗалыкларга да барып булыштылар. Шул исәптән Муса Җәлил исемендәге хуҗалыкта җиргә сыланган бодайны нинди авырлык белән суктырып алганнарын бер үзләре генә беләләр.

Уңган механизатор бүген хуҗалыкның ремонт мастерскоенда, һәр механизаторның гозере төшәрдәй вазифада.

**Н.АЗИЗОВ фотосы.**

## «Төрнәс» - беренче

«Төрнәс» крестьян хуҗалыклары ассоциациясе игенчеләре дәүләткә шикәр чөгендере сату буенча килешү йөкләмәсен районда беренче булып тутырдылар. Норлат шикәр заводына бу хуҗалыктан йөкләмәдәге 890 тонна урынына 924 тонна чимал керде инде. Чөгендерне планнан тыш сату дәвам итә. Татлы тамырның әле казыласы да булуын искә алганда, хуҗалыктан шикәр чималы тагын шактый керәчәк әле.

Кичәге көнгә татлы тамыр район буенча барлык мәйданның 60 процентыннан диярлек казып алынды. «Кондырча»да һәм «Агрохимсервис»ның ярдәмче хуҗалыгында бу эш тәмамланды дияргә мөмкин инде. «Якты Күл», «Заветы Ильича» хуҗалыкларында, заводның ярдәмче хуҗалыгында шикәр чөгендере барлык мәйданның 70 - 72 процентыннан казып алынды.

Район хуҗалыкларыннан шикәр заводына 33 мең тоннага якын чимал керде.

## Кайда күпме сөт саудылар?

*Саннарның беренче баганасы-район хуҗалыкларында 9 айда, икенче-сентябрьдә бер сыердан савылган сөт (килограммнарда).*

| | | |
|---|---|---|
| «Кондырча» | 5226 | 455 |
| «Дуслык» | 5187 | 437 |
| Мичурин исем. | 4606 | 655 |
| «Агрохимсервис» ярд.хуҗ. | 3761 | 351 |
| «Рассвет» | 3600 | 383 |
| «Якты Күл» | 3486 | 394 |
| Хафизов исем. | 3309 | 315 |
| Шикәр заводы ярд.хуҗ. | 3258 | 322 |
| «Киекле» | 3131 | 360 |
| «Родина» | 2970 | 296 |
| «Чирмешән» | 2969 | 265 |
| «Заветы Ильича» | 2924 | 239 |
| М.Җәлил исем. | 2856 | 275 |
| Синдряков исем. | 2801 | 240 |
| Кузнецов исем. | 2774 | 312 |

| | | |
|---|---|---|
| «1нче Май» | 2719 | 319 |
| Сөт-май комбинаты ярд.хуҗ. | 2684 | 256 |
| «Татарстан» | 2648 | 280 |
| «40 лет Победы» | 2571 | 248 |
| «Төрнәс» | 2569 | 274 |
| «Заря» | 2434 | 235 |
| Нефтебаза ярд.хуҗ. | 2357 | 211 |
| РСУ ярд.хуҗ. | 2313 | 231 |
| «Таң» | 2286 | 274 |
| «Үрнәк» | 2281 | 201 |
| «Әлмәт» | 2131 | 214 |
| «Игенче» | 2121 | 218 |
| «Алга» | 2018 | 252 |
| МСО | 1953 | 194 |
| «Комбайн» | 1679 | 157 |
| **Район буенча** | **2794** | **290** |

Район буенча сыерларның тугыз айлык продуктлылыгы узган елның шул чорындагыдан 752 килограммга күбрәк булды,тулаем сөт җитештерү өчтән бер тапкырга диярлек артты.

Сентябрьне дә узган елның шул аендагыдан яхшырак нәтиҗәләр белән төгәлләдек.Бу яктан Мичурин исемендәге,«Киекле»,«Якты Күл»,«Алга» да, «Агрохимсервис» һәм шикәр заводы ярдәмче хуҗалыгында аеруча зур алга китеш сакланган бер вакытта,«Дуслык»,МСО ярдәмче хуҗалыкларында,«Кондырча»,«Үрнәк» һәм «Таң» сентябрьне «минус»лы күрсәткеч белән төгәлләделәр.




## КИРЕ КАЙТТЫК

Билгеле булганча, моннан 445 ел элек Казан ханлыгы яулап алына. Шул максаттан чыгып, укучылар һәм мәктәп коллективы дәүләтчелегебезне саклап калучы борынгы ата - бабаларыбызны искә төшерү йөзеннән тантаналы линейкага җыелдылар.

«... 2 октябрьдә Казанга гомуми һөҗүм башлана. Башта шәһәрне утка тоталар. Таң алдыннан Аталык һәм Нугай капкалары янында бер үк вакытта котычкыч ике шартлау гөрселди - анда дары тутырылган 48 мичкә шартлатыла. Шәһәр ныгытмасы ике урыннан киң аралык ясап җимерелеп төшә һәм шуның аша руслар ташкыны килеп керә. Шәһәр эчендә чын мәгънәсендә сугыш башлана. Татар каны елга булып ага, мәетләр аша үтеп йөргесез була. Казан җиңелә...»

Тарих дәреслекләрендә язылган бу юллар һәр укучы баланың йөрәгенә үтеп керерлек. Дөрестән, 1552 елда Иван Грозный гаскәрләренең Казанны яулап алуын һәр бала белергә тиеш. Чөнки бу - безнең тарих.

Тарих укытучысы, укытучы - методист Әхәт Минәхмәтович Хәмәтҗанов балалар алдында чыгыш ясап, Алтын Урда, Болгар чоры һәм Казан ханлыклары турында мәгълүмат бирде. Бу дәүләтләрнең мәдәнияты белән таныштырды, көчләп чукындыруга да киң тукталды. Иң әһәмиятлесе, милләтебезнең фаҗигале язмышын, милләт буларак халыкларны юк итү сәясәтенең алып барылуын, Казан тирәсеннән татар халыкларын куып, урысларны урнаштыруларына да тукталды.

Ләкин милләтебез үз йөзен югалтмады. Шул ук вакытта бик урынлы рәвештә Тукай шигыреннән өзек тә китерде:

Без сугышта юлбарыстан көчлебез,
Без тынычта аттан артык эшлибез.

Хәтер көнендә тарихыбызны белү кирәклегенә аеруча басым ясап әйтелде. Мисал итеп, милли азатлык өчен көрәшүчеләрдән Гаяз Исхакый, Садри Максуди, Идрис Туктаров, мәгърифәтчеләребез - Каюм Насыйри, Шиһабетдин Мәрҗәни, Габделҗаббар Кандалыйлар китерелде. Укучыларга бу шәхесләрне, аларның иҗатын яхшы өйрәнергә тиешлекләре искәртелде.

Безнең Республикабызның бүгенге сәясәте дә изге: ул - тынычлыкны саклау. Татарстан - Россиядә иң тыныч регионнардан санала. Бездә халыкларны социаль яктан яклау да алгы планга куелган. Без урып - җыю чорында да сынатмадык. Россиянең кайбер регионнарына караганда икмәкне бик күпкә арттырып җитештердек. Үз байлыгыбызны да үзебез кулланабыз. Чит илләр белән турыдан - туры элемтәгә чыга алабыз. Биредә әлбәттә Президентыбыз Минтимер Шәймиевнең роле зур. 1552 елгы сугышлар кире кабатланмасын өчен, аның зирәклегенә, сәяси өлгерлегенә ышанырга кала.

**Г.ФӘСХЕТДИНОВА.**
**Кәкре Атау.**

## Хөрмәтле дуслар!

1998 елның беренче яртыеллыгына газетага язылу бара. Язылу бәясе ярты елга 26.400, өч айга - 13.200, бер айга - 4.400 сум.

Район газетасына язылырга ашыгыгыз! Ул һәрвакыттагыча сезгә яңалыклар, хәбәрләр, кызыклы киңәшләр белән бергә атналык телетапшырулар программасын да даими биреп барачак.

### Урамнарыбыз алар исемен йөртә

# Н.И.ЛОБАЧЕВСКИЙ урамы



Николай Иванович Лобачевский (1792 - 1856) - атаклы рус математигы, Евклидча булмаган геометрияне төзүче, материалист фикер иясе, университет белеме бирү һәм халык мәгарифе эшлеклесе.

Түбән Новгородта вак чиновник гаиләсендә туган. Әмма бөтен гомерен Казанда үткәргән. Биредә ул башта гимназиядә, аннан Казан университетында укыган. Гаять сәләтле булып танылып, ул университетны тәмамлаганда ук магистр дәрәҗәсе ала һәм шунда эшкә калдырыла. Шунда башта адъюнкт, экстраординар, ә аннан ординар профессор була.

Фәнни һәм педагогик эшчәнлек белән киеренке шөгыльләнә. Студентлар аның лекцияләренә бик яратып йөриләр. Лобачевский биредә китапханәгә, обсерваториягә җитәкчелек итә, физика - математика факультетының деканы итеп сайлана.

1827 елда Лобачевский университетның ректоры итеп сайлана һәм 19 ел буе җитәкчелек итү чорында бу уку йортының чәчәк атуына ирешә. Шул чорда университет биналарының тулы комплексы төзелә һәм Казан университеты көнчыгышны өйрәнүнең әһәмиятле үзәгенә әверелә.

Лобачевский гимназияләрдә һәм училищеларда укытуны яхшырту эшенә дә күп көч куя, физикадан халык өчен фәнни - популяр лекцияләр бастырып чыгара.

Лобачевскийның Евклидча булмаган геометриясе - математика фәненә кертелгән гаять күренекле зур өлеш. Аның фәнни хезмәтләре чит илләрдә дә нәшер ителә. Николай Иванович Лобачевскийның исеме һәм хезмәте аның 100 еллыгы уңаеннан аеруча киң таныла. Аның исемендәге халыкара премия булдырыла. Казанда аңа һәйкәл куелган, аның исеме бер урамга бирелгән, университетның фәнни китапханәсе дә -аның исемендә.

# Газета алдыручы укый, газета язучы саный




«Дуслык» район газетасына язылу дәвам итә. Бүгенге көнгә 7300дән артык укучы аңа язылдылар. Иң оператив һәм зур һәм кечкенә вакыйгалар турында киң информация бирүче чыганаксыз ничек мөмкин соң? Без беләбез, газетага язылучыларның зур күпчелеге пенсионерлар - сезнең безгә тугрылыклы булып калуыгыз өчен рәхмәт, дуслар. Без үз чиратыбызда газетаның санын җыеп сезнең кызыксынуыгыз турында онытмаска тырышабыз: кайтаваз хатлар бастырабыз, өлкән кешеләрнең тормышы, көнкүреше, ихтыяҗлары турында сөйлибез, кызыклы биографияләр белән таныштырабыз. Менә бу көннәрдә дә без газета битләрендә «1 - 10 октябрь өлкән кешеләр декадасы» рубрикасын ачтык. Киләсе 1998 елда да безнең белән калыгыз.

Район газетасына льготалы бәядән язылу туры килгән 8 - 18 нче сентябрьдә газетага күп кеше язылды. Шул көннәрдә генә дә 7000гә якын кеше квитанция тутырды. Елаур, Якушкино, Гәйтән, Богдашкино, Түбән Чаллы, Егоркино, Киекле һәм Вишневая Поляна авылларындагы элемтә бүлекләрендә газетага язылу аеруча актив барды. Ә менә Андреевка, Кычытканлы, Иске Әлмәт, Колбай Мораса, Тумба, Чуваш Тимерлеге, Яңа Иглай, Кизләү авылларында һәм Бутаиха поселогында бу көннәрдә газетага бик аз кеше язылды. Әмма газетага язылу тәмамланырга вакыт шактый әле. Һәм, билгеле инде, безнең укучыларыбыз саны да артачак.

Беләбез, күпләрегез район газетасының әр яңа санын ачып һичшиксез уйлап куя: «Ни өчен бу турыда аз язалар...» яисә «Әгәр дә мин редакциядә эшләсәм, менә бу... теманы игътибарсыз калдырмас идем». Без газета укучылардан үз фикерләре һәм тәкъдимнәре белән уртаклашуларын сорап мөрәҗәгать иттек. Алардан менә ниләр ишеттек.

***Людмила Васильевна Тафеева*** безнең укучыбыз һәм авторларыбызның берсе.

- Район газетасын яшь чагымнан алдырам. Ул бит район тормышын һәрьяклап яктырта. Район газетасына күңел өчен - кешеләр турында җылы итеп язылган язмалар яисә шигырьләрне ешрак бастыруларын теләр идем, кеше бит икмәк белән генә тук түгел.

***Клавдия Ивановна Гаврилова,*** Яңа Тумба җирле үзидарә Советы бухгалтеры.

- Мине яңалыклар турында сөйләнә торган беренче бит материаллары кызыксындыра. Без район үзәгеннән читтә яшәсәк тә һәрнәрсә белән кызыксынабыз. Бюджет, салым салу һәм башкалар, бер сүз белән әйткәндә эшем өчен кирәкле нәрсәләр турындагы язмаларны зур игътибар белән укыйм.

***Юрий Владимирович Терентьев***, район хакимияте башлыгының беренче урынбасары.

- Газетаны компьютер ярдәмендә җыю һәм версткалау аның йөзен төптән үзгәртте. Тулаем алганда да соңгы елларда аның эчтәлеге баеды. Биредә белгечләрнең технологик мәсьәләләр буенча язмалары, тематик агрокүзәтүләр басыла. Район газетасына һәр гаиләнең язылуына ирешергә кирәк - шул чакта гына халык районның бүгенгесе һәм киләчәге турында кирәкле һәм объектив информация белән коралланa алачак. Һәм минем уемча газета белән күбрәк җәмәгать хәбәрчеләре хезмәттәшлек итәргә тиешләр.

Безнең даими укучыларыбызга киңәшләре, фикерләре һәм тәкъдимнәре өчен бик зур рәхмәт. Без аларны үз эшебездә һичшиксез кулланырга тырышачакбыз. Ә «Дуслык»ка язылмаган кешеләрнең янә исләренә төшерәбез: соңга кала күрмәгез.

# Ветераннар җырлый, ветераннар ...

Якыннарының җылы кайгыртуына һәм аена бер өеңә пенсияңне тотып хат ташучы килүенә шәхси мәшгульлекне дә өстәсәң генә картлыгың тулы канлы һәм җайлы буладыр, мөгаен. Әйтик, шигырьләр язу, көй иҗат итү яки фотога төшерү - иң мөһиме, җаның теләгән шөгыль белән яшәү. Ә менә сез рәсемдә күргән сөйкемле хатын - кызларны җырга гашыйклык берләштерә. Инде берничә ел алар район мәдәният йорты каршындагы «Ветеран» хорында җырлыйлар, район халкы, кунаклары алдында бәйрәм концертларында катнашалар.



Чыгышларын зур канәгатьлек белән, яшьлектәгечә җаннары - тәннәре белән бирелеп башкаралар. Репертуарларында безгә иң таныш һәм күңелгә якын - язмыш, хатын - кыз турында тормышны яратуга багышланган хисләр җан җылысы белән җырлана.

**Рәсемдә: «Ветеран» хоры җырлый.**

# КОТЛЫЙБЫЗ!

Норлатта яшәүче кадерле әниебез, әбиебез, апабыз **Миннегөл Мингалим кызы Закировага** 75 яшь тула. Аны чын күңелдән туган көне белән котлап, ныклы исәнлек, озын гомер, җан тынычлыгы телибез.

Йөзең ачык, күңелең киң,<br>
Без диеп гел яшисең.<br>
Безнең хөрмәтне дә тоеп,<br>
Озак еллар яшә син.

**Балалары, оныклары, туганнары.**

# Рәхмәт

Бу дөньяда күп нәрсә күрергә туры килде миңа. Шуңа да кешеләрнең бер - берсенә җылы мөнәсәбәтләрен югары бәялим. Ике елымны блокадалы Ленинградта үткәрдем - сәламәтлегемне дә шунда югалттым инде. 1960 нчы елда Норлатка кайттым, шикәр заводында, район элемтә бүлегендә газета сортладым. Хәзер пенсиядә. Әмма күз һәм яз, ревматизм һәм полиартрит көчәйгәндә, авыртуларым көчәя. Быел район үзәк шифаханәсе табибларына ярдәм сорап мөрәҗәгать иттем. Терапевт Тамара Васильевна Пермякова, шәфкать туташы Фәридә Ибәтуллина мине аякка бастыру өчен көчләрен дә, вакытларын да кызганмадылар. Алар кабул иткәндә дә миңа бик игътибарлы булдылар, өемә килеп төрле инъекцияләр ясадылар.

Район шифаханәсендә дә мин үземә кирәкле барлык даруларны да ала алдым. Саулык - сәламәтлек, яңа көч һәм гаилә иминлеге сезгә!



**М.МОРАТОВА.**
**Норлат шәһәре, Победа урамы.**

# Аракыга - махсус марка

1996 елдан бирле кулланучылар хокукын саклау буенча Октябрь район комитеты каршында дәүләт алкоголь инспекциясе эшләп килә. Инспекция дәүләт һәм шәхси сәүдә предприятиеләрендә алкогольле эчемлекләр белән сәүдә итү тәртибен күзәтеп, даими тикшереп тора. Инспектор М.С.Райманова әйтүенчә, һәр тикшерү аракы сату кагыйдәләре бозу очракларын еш күрсәтә. Ләкин андыйлар җәзадан җиңел генә котыла алмыйлар: тиешле таләпләрне үтәмәү бик кыйммәткә төшә - 50 - 100 минималь хезмәт хакына кадәр җитә.

Ә менә 15 нче октябрьдән соң әлеге административ җәзага таручылар саны бермә - бер артуы да ихтимал, чөнки ТР Министрлар Кабинетының «ТР территориясендә җитештерелә торган алкогольле продукцияне маркалау өчен махсус маркалар турында»гы карары нигезендә (13 нче август 1997 ел) шул көннән башлап махсус маркалар белән маркаланмаган алкогольле продукция белән сәүдә итү тыелачак. Шул карарда каралганча махсус маркалар металлограф ысулы белән басылырга һәм тәртип номерында үз эченә алырга тиеш. Димәк, 15 октябрьдән соң район кулланучылар хокукын саклау комитеты тарафыннан алкогольле эчемлекләрне ваклап сату предприятиеләренә, эшмәкәрләренә карата таләпләре тагын да катгыйрак төс алачак.

## *Синең кешеләрең , авыл*

# Тәүге сынау



Илсур яшь кенә булса да үзен производствоның төрле өлкәләрендә сынап карарга өлгерде инде. Чистайда совхоз - техникум тәмамлагач, механик та, ягулык салучы да, тәэминатчы да булып эшләде.

- Сайлаган һөнәрең буенча хәзерлек дәрәҗәңне төрле яклап сынап зур тормышка хәзерлекне түбәннән башларга кирәк дип саныйм, ди егет кистереп. Узган ел 1,5 эксплуатация срогы узган иске «КамАЗ» автомашинасы рамасыннан үз куллары белән машина җыярга ниятли Илсур. Ничек итсә итә, әмма ния тенә ирешә егет һәм шул машинасы белән районадагы байтак шоферларның борынына чиртә дә.

Илсурның шофер буларак тәүге тапкыр уракта катнашуы иде быел. «КамАЗ»ы белән басудан ындыр табагына ашлык ташу бурычы куелды аның алдына. Иртән - иртүк, комбайннар басуга килеп басуга ук Илсур анда була иде инде. Һава шартларына карап, кыр корабларының кайчан суктыруга төшүләрен белешә дә, вакытын әрәм итмичә ындыр табагына ашыга: элеваторга берәр рейс ашлык илтеп кайтырга өлгереп була әле. Шуңа әрҗәсенә икмәкне төйи дә юлга кузгала. Ә Камышлыдан элеваторга кадәр ара аның өчен чүп тә түгел: санаулы минутлар эчендә «КамАЗ»ын кабул итү пунктына китерә дә бастыра. Ә биредә, соңгы елларда, шөкер, чират - мазар юк, тоткарлык тудырмыйча озаталар автотранспортчыларны.

Илсур басуга нәкъ комбайннар эшкә тотынган вакытка кайтып җитә. Ун тонна сыешлы әрҗәсенә 4 бункер ашлык салдыра да - «выжт» ындыр табагына. Көненә 20 - 23әр тапкыр әйләнергә туры килә басу белән ындыр табагы арасын. Билгеле инде, чын - чынлап эшлим дигән кеше өчен шоферлар арасындагы конкуренцияне дә даими җиңеп барырга кирәк. Ашлык суктыру белән мәшгуль 8ләп комбайннан ашлык ташучы 4 машинага «корабларның» бункер тутыруын чын мәгънәдә «сагалап» йөрергә туры килә. Илсур исә андый сыната торган егетләрдән түгел: үз алдына куелган максаты ачык, вакытының һәр минуты исәптә. Эшләргә икән инде нәтиҗәсе дә, акчасы да уч тутырып алырлык булсын. Шул ук вакытта үзенең хезмәт мөмкинлекләрен дә билгеләп, сынарлык шартлар кирәк аның өчен. Шуңа да кич, үләннәр өстенә чык төшеп, караңгыда комбайннар уйсулыктагы мәйданнардан өскерәк, корырак участокка күчкәндә дә, кайберәүләр кебек өенә кайтып китеп, ял итү мөмкинлеген эзләми Илсур. Ярты төнгәчә, кайчакта сәгать берләргә кадәр ашлык ташый. Туган җире Югары Норлат авылына кайтканда да төннең икенче яртысы дип тормый, Камышлыдан элеваторга йөк төяп кайта. Ә инде иртән, авыл көтү куганда Илсур Мөхәммәтов «КамАЗ»ы белән янә юлда була. Берничә ел эшләп, хуҗалыгы да, кешеләре дә күңеленә якынайган Камышлыга юл тота ул. Шулай эшләмәгән булса, басудан ындыр табагына 40000 центнердан артык ашлык та кайтара алмаган булыр иде.

- «КамАЗ»ым бер генә тапкыр да сынатмады, шуңа бик сөенәм,- ди ул самими шатлык белән - димәк, дөрес итеп җыйганмын.

Техниканы чын - чынлап яраткан кеше генә шулай сөенәдер, мөгаен. Ә инде ул машина үз хәләл көчең белән җыелганда, аның йөрәгеңә сабыең кебек якын булуы табигый шул.

- Күңел романтикага ашкына, канәгатьләнү белми, тагын нәрсәдер җыясы, майтарасы килә,- ди Илсур.

- Бәлки, самолеттыр...

- Сынап карарга мөмкин...

Димәк, тагын да зуррак уңышлары, казанышлары алда әле егетнең.

**Р.ГИНЯЕВА.**

**Рәсемдә: И.Мөхәммәтов.**

**Н.АЗИЗОВ фотосы.**

---

## ИГЪТИБАР: КИЧҮ

**Соңгы вакытта Татарстан Республикасында тимер юл аша чыгу юлыннан автомототранспорт чаралары үтүенә бәйләнгән юл - транспорт һәлакәтләре очраклары ешайды. Октябрь районы территориясендә җиде тимер юл кичүе булса, шуларның бары тик берсе генә саклана. Бу күренеш шоферларның тагын да җаваплырак булуын таләп итә, әлбәттә, ләкин контрольсезлек кайберәүләргә билгеләнгән кагыйдәләрне бозуга да юл куя кайчак. Соңгысын аңлатуы кыен, чөнки мондый күренешләр еш кына аяныч нәтиҗәләргә китереп чыгара.**

**Шул уңайдан транспорт чаралары ияләренә элементар кагыйдәләрне искә төшерәсе килә.**

**Тимер юл аркылы чыгар алдыннан двигательнең ныклы эшчәнлеген тәэмин итү өчен дөрес хәрәкәт режимын сайлау зарур. Кичүгә поезд якынлашканда аркылы юлга керергә ашыкмагыз. Локомотив шәүләсеннән, бигрәк тә аның фараларыннан төшкән ут яктысыннан хәтта якынча да поезд тизлеген һәм кичүдән ераклыгын билгеләү мөмкин түгел. Тукталыгыз һәм поезд узып киткәнне көтегез. Аны бит кинәт кенә туктатып булмый. Машинист көтелмәгән тормоз чараларын кулланган очракта поезд 800 - 1000 метр үткәч кенә туктый. Кичү светофорлары поезд якынлашуы һәм хәрәкәтнең тыелуы турында поезд килеп җитәргә 30 - 40 секунд калгач кына кызыл төстәге сигнал белән хәбәр итәләр. Шуңа да транспорт белән кичүгә җиткәндә игътибарны сөйләшүгә юнәлдерергә ярамый. Шулай ук кичүгә якынлашканда алда торган транспорт арасында дистанция калдыру мөһимлеген дә онытмагыз.**

**Алда кыш - транспорт хезмәткәрләре өчен иң җаваплы чор. Бу вакыт күз күрүчәнлеге, юлларның начараюы, көн яктылыгы кыскаруы белән характерлана. Транспорт ияләренә мөрәҗәгать итәбез: үзегезне дә, сезгә ышанып юлга чыккан пассажирларны да куркыныч астына куймагыз. Туганнарыгыз һәм якыннарыгызның иминлеге сезнең кулда.**

**А.КАЮМОВ,**

**Октябрь районы эчке эшләр бүлегенең юл күзәтчелеге дәүләт автоинспекторы.**

---



# Тырышлар алар

Үз эшенең остасы булган, тырыш кешеләр эштә дә, гомумән, тормышта да һәрчак кеше арасында булалар. Ярдәм сорап, тәҗрибәсен өйрәнергә дип, кайчак акыллы кешедән яхшы сүз ишетергә дип андыйлар янына магниттай тарталалар. Хәмит тә һәрчак халык арасында. Кемдер аның ярдәменә өмет итеп киңәш сорый, икенче берәү практик ярдәм һ.б. Шулай булмый ни: Кыямов «40 лет Победы» КХАнда иң булдыклы механизаторларның берсе бит. Теләсә нинди техника буйсына аңа. Урак чорында тәүге тапкыр комбайн штурвалы артына утырганын күпләр хәтерләмиләр дә инде. Хәмит исә бер генә уракта да сынатканы булмады. Быел да «ДОН - 1500» комбайны бункерыннан иң күп ашлыкны Кыямов бушатты.

Газыймҗан Мостафин исә быел җәй буе Хәмит янәшәсендә булды. Юк, аның ярдәмчесе түгел ул. Газыймҗан үзе «Нива» белән игеннәр уңышын җыйды. Тырышлыгы көчле аның, шуңа да тәҗрибәсен баету өстендә дә даими, максатчан эшли. Ә янәшәңдә Хәмит кебекләр булганда күп нәрсәгә өйрәнеп була.

**Рәсемдә: Х.Кыямов, Г.Мостафин.**

**Н.АЗИЗОВ фотосы.**

---

# Ялгызларны ялгыз итмиләр

Табигатьтә елның фасыллары төрле булган кебек гомернең дә язы,җәе,көзе бар.Көзе әлбәттә,картлык. Без, өлкәннәргә кадер-хөрмәт,дип сөйләнсәк тә, кызганыч, дөреслеккә бик туры килеп бетми.Аларның,караучысыз клып урам-вокзалларда куна-төнә җан асраучылары да юк түгел. Кайсыберләре балалары исән килеш картлар йортында тилмерә. Шөкер,авылда хәл ул кадәр аяныч түгел. Авылда шәфкать-миһырбанлык бетмәгән. Караучысыз калган ялгыз карт-карчыкларны язмыш иркенә ташламыйлар. Хуҗалык, җирле үзидарә булыша,тирә-күршеләре ярдәм итә. Күрше хакы-тәңре хакы, диләр бит.Әнә шундый миһербанлы җаннар барында әбекәйләр картлар йорты тәрәзәләреннән карашларын еракларга төбәп сагыну-сагыштан саргаеп кипмәячәк.Бикүле авылында да караучысыз калган өлкәннәрне карап,тәрбияләп,җирле үзидарә Советы рәисе урынбасары Сания апа Батталова әйтмешли, «шәфкатьлелек үрнәге булып яшәүче» гаиләләр бар.Шуларның берсе Мөхәммәтҗановлар гаиләсе, Ислам абый белән Сания апа. Киң күңелле,ачык йөзле кешеләр. 1962 елда гаилә корып,биш бала үстереп,гомерләре буе туган авылларында эшләп яшәгәннәр. Хәзер лаеклы ялда.Балаларына оныкларын тәрбияләшәләр һәм... күршеләрендәге ятимә әбине карап торалар.Әти-әниләре -ике сугыш кичкән Кәрим бабай белән авылда тормышның ачысын-төчесен күргән Минбәян әбине кадер-хөрмәттә генә яшәтеп олылап соңгы юлга озаттылар.Үзен-үзе карый алмый башлагач, күршеләре Бәнат әби Сафиуллинаны үз тәрбияләренә алалар. Әбекәй,берничә еллар яшәп,үз балаларыдай кадерле күршеләренә хәер - догасын,бәхилләгән биреп якты дөнья белән хушлаша.Мусина Нургаян әби дә Ислам абый белән Сания апа гаиләсендә терәк,таяныч таба.Җеназасы алар нигезеннән чыга.Бүген Мөхәммәтҗановларда Сәрбиҗамал әби Исхакова яши.Нужаны,ялгызлыкны җитәрлек күргән әбинең күңеле тыныч,намазын укый, гамәлен кыла.Үзен тәрбияләүчеләргә теләкләр тели.Аны хөрмәт итәләр. «Әби утырмыйча бездә чәй янына утыру гадәте юк»,-ди Сания апа. Үзләре янында яшәүче уллары Илһам белән киленнәре Илсөярнең кечкенә кызлары да «Сәрбиҗамал әбети» дип гел әби тирәсендә бөтерелә. Димәк, өлкәннәрне хөрмәт итәргә кечкенәдән өйрәнеп үсә. Мөхәммәтҗановлар әнә шулай башкаларга игелек кылып мул,тату тормышта гомер итәләр. Бик күпләргә үрнәк алар.

Шөкер, мондый шәфкать-миһербанлы гаиләләр авылыбызда җитәрлек.Бикүленең үзендә тагынМинтаһир һәм Рәхимә Хәсәнҗановлар,Иске Авылда Равил һәм Затия Кәлимуллиннар,Кәкре Атаудан Зәкиулла һәм Фатыйма Садыйковлар, Дамир һәм Сәгадәт Алишевлар гаиләләре ялгыз әбиләрне карап,ярдәм итеп яшиләр. Үзләренең игелекле эш-гамәлләре белән алар күпләр өчен үрнәк.Ә изгелек җирдә ятмый ул.

**Җ.ШАКИРОВ.**

*Синең кешеләрең, авыл*

# Тәүге сынау

Илсур яшь кенә булса да үзен производствоның төрле өлкәләрендә сынап карарга өлгерде инде. Чистайда совхоз - техникум тәмамлагач, механик та, ягулык салучы да, тәэминатчы да булып эшләде.

- Сайлаган һөнәрең буенча хәзерлек дәрәҗәңне төрле яклап сынап зур тормышка хәзерлекне түбәннән башларга кирәк дип саныйм, ди егет кистереп. Узган ел 1,5 эксплуатация срогы узган иске «КамАЗ» автомашинасы рамасыннан үз куллары белән машина җыярга ниятли Илсур. Ничек итсә итә, әмма ния тенә ирешә егет һәм шул машинасы белән райондагы байтак шоферларның борынына чиртә дә.

Илсурның шофер буларак тәүге тапкыр уракта катнашуы иде быел. «КамАЗ»ы белән басудан ындыр табагына ашлык ташу бурычы куелды аның алдына. Иртән - иртүк, комбайннар басуга килеп басуга ук Илсур анда була иде инде. Һава шартларына карап, кыр корабларының кайчан суктыруга төшүләрен белешә дә, вакытын әрәм итмичә ындыр табагына ашыга: элеваторга берәр рейс ашлык илтеп кайтырга өлгереп була әле. Шуңа әрҗәсенә икмәкне төйи дә юлга кузгала. Ә Камышлыдан элеваторга кадәр ара аның өчен чүп тә түгел: санаулы минутлар эчендә «КамАЗ»ын кабул итү пунктына китерә дә бастыра. Ә биредә, соңгы елларда, шөкер, чират - мазар юк, тоткарлык тудырмыйча озаталар автотранспортчыларны.



Илсур басуга нәкъ комбайннар эшкә тотынган вакытка кайтып җитә. Ун тонна сыешлы әрҗәсенә 4 бункер ашлык салдыра да - «выжт» ындыр табагына. Көненә 20 - 23әр тапкыр әйләнергә туры килә басу белән ындыр табагы арасын. Билгеле инде, чын - чынлап эшлим дигән кеше өчен шоферлар арасындагы конкуренцияне дә даими җиңеп барырга кирәк. Ашлык суктыру белән мәшгуль 8ләп комбайннан ашлык ташучы 4 машинага «корабларның» бункер тутыруын чын мәгънәдә «сагалап» йөрергә туры килә. Илсур исә андый сыната торган егетләрдән түгел: үз алдына куелган максаты ачык, вакытының һәр минуты исәптә. Эшләргә икән инде нәтиҗәсе дә, акчасы да уч тутырып алырлык булсын. Шул ук вакытта үзенең хезмәт мөмкинлекләрен дә билгеләп, сынарлык шартлар кирәк аның өчен. Шуңа да кич, үләннәр өстенә чык төшеп, караңгыда комбайннар уйсулыктагы мәйданнардан өскерәк, корырак участокка күчкәндә дә, кайберәүләр кебек өенә кайтып китеп, ял итү мөмкинлеген эзләми Илсур. Ярты төнгәчә, кайчакта сәгать берләргә кадәр ашлык ташый. Туган җире Югары Норлат авылына кайтканда да төннең икенче яртысы дип тормый, Камышлыдан элеваторга йөк төяп кайта. Ә инде иртән, авыл көтү куганда Илсур Мөхәммәтов «КамАЗ»ы белән янә юлда була. Берничә ел эшләп, хуҗалыгы да, кешеләре дә күңеленә якынайган Камышлыга юл тота ул. Шулай эшләмәгән булса, басудан ындыр табагына 40000 центнердан артык ашлык та кайтара алмаган булыр иде.

- «КамАЗ»ым бер генә тапкыр да сынатмады, шуңа бик сөенәм,- ди ул самими шатлык белән - димәк, дөрес итеп җыйганмын.

Техниканы чын - чынлап яраткан кеше генә шулай сөенәдер, мөгаен. Ә инде ул машина үз хәләл көчең белән җыелганда, аның йөрәгеңә сабыең кебек якын булуы табигый шул.

- Күңел романтикага ашкына, канәгатьләнү белми, тагын нәрсәдер җыясы, майтарасы килә,- ди Илсур.

- Бәлки, самолеттыр...

- Сынап карарга мөмкин...

Димәк, тагын да зуррак уңышлары, казанышлары алда әле егетнең.

**Р.ГИНЯЕВА.**

**Рәсемдә: И.Мөхәммәтов.**

**Н.АЗИЗОВ фотосы.**

## ИГЪТИБАР: КИЧҮ

Соңгы вакытта Татарстан Республикасында тимер юл аша чыгу юлыннан автомототранспорт чаралары үтүенә бәйләнгән юл - транспорт һәлакәтләре очраклары ешайды. Октябрь районы территориясендә җиде тимер юл кичүе булса, шуларның бары тик берсе генә саклана. Бу күренеш шоферларның тагын да җаваплырак булуын таләп итә, әлбәттә, ләкин контрольсезлек кайберәүләргә билгеләнгән кагыйдәләрне бозуга да юл куя кайчак. Соңгысын аңлатуы кыен, чөнки мондый күренешләр еш кына аяныч нәтиҗәләргә китереп чыгара.

Шул уңайдан транспорт чаралары ияләренә элементар кагыйдәләрне искә төшерәсе килә.

Тимер юл аркылы чыгар алдыннан двигательнең ныклы эшчәнлеген тәэмин итү өчен дөрес хәрәкәт режимын сайлау зарур. Кичүгә поезд якынлашканда аркылы юлга керергә ашыкмагыз. Локомотив шәүләсеннән, бигрәк тә аның фараларыннан төшкән ут яктысыннан хәтта якынча да поезд тизлеген һәм кичүдән ераклыгын билгеләү мөмкин түгел. Тукталыгыз һәм поезд узып киткәнне көтегез. Аны бит кинәт кенә туктатып булмый. Машинист көтелмәгән тормоз чараларын кулланган очракта поезд 800 - 1000 метр үткәч кенә туктый. Кичү светофорлары поезд якынлашуы һәм хәрәкәтнең тыелуы турында поезд килеп җитәргә 30 - 40 секунд калгач кына кызыл төстәге сигнал белән хәбәр итәләр. Шуңа да транспорт белән кичүгә җиткәндә игътибарны сөйләшүгә юнәлдерергә ярамый. Шулай ук кичүгә якынлашканда алда торган транспорт арасында дистанция калдыру мөһимлеген дә онытмагыз.

Алда кыш - транспорт хезмәткәрләре өчен иң җаваплы чор. Бу вакыт күз күрүчәнлеге, юлларның начараюы, көн яктылыгы кыскаруы белән характерлана. Транспорт ияләренә мөрәҗәгать итәбез: үзегезне дә, сезгә ышанып юлга чыккан пассажирларны да куркыныч астына куймагыз. Туганнарыгыз һәм якыннарыгызның иминлеге сезнең кулда.

**А.КАЮМОВ,**

**Октябрь районы эчке эшләр бүлегенең юл күзәтчелеге дәүләт автоинспекторы.**



# Тырышлар алар

Үз эшенең остасы булган, тырыш кешеләр эштә дә, гомумән, тормышта да һәрчак кеше арасында булалар. Ярдәм сорап, тәҗрибәсен өйрәнергә дип, кайчак акыллы кешедән яхшы сүз ишетергә дип андыйлар янына магниттай тартылалар. Хәмит тә һәрчак халык арасында. Кемдер аның ярдәменә өмет итеп киңәш сорый, икенче берәү практик ярдәм һ.б. Шулай булмый ни: Кыямов «40 лет Победы» КХАнда иң булдыклы механизаторларның берсе бит. Теләсә нинди техника буйсына аңа. Урак чорында тәүге тапкыр комбайн штурвалы артына утырганын күпләр хәтерләмиләр дә инде. Хәмит исә бер генә уракта да сынатканы булмады. Быел да «ДОН - 1500» комбайны бункерыннан иң күп ашлыкны Кыямов бушатты.

Газыймҗан Мостафин исә быел җәй буе Хәмит янәшәсендә булды. Юк, аның ярдәмчесе түгел ул. Газыймҗан үзе «Нива» белән игеннәр уңышын җыйды. Тырышлыгы көчле аның, шуңа да тәҗрибәсен баету өстендә дә даими, максатчан эшли. Ә янәшәңдә Хәмит кебекләр булганда күп нәрсәгә өйрәнеп була.

**Рәсемдә: Х.Кыямов, Г.Мостафин.**

**Н.АЗИЗОВ фотосы.**

# Ялгызларны ялгыз итмиләр

Табигатьтә елның фасыллары төрле булган кебек гомернең дә язы,җәе,көзе бар.Көзе әлбәттә,картлык. Без, өлкәннәргә кадер-хөрмәт,дип сөйләнсәк тә, кызганыч, дөреслеккә бик туры килеп бетми.Аларның,караучысыз клып урам-вокзалларда куна-төнә җан асраучылары да юк түгел. Кайсыберләре балалары исән килеш картлар йортында тилмерә. Шөкер,авылда хәл ул кадәр аяныч түгел. Авылда шәфкать-миһырбанлык бетмәгән. Караучысыз калган ялгыз карт-карчыкларны язмыш иркенә ташламыйлар. Хуҗалык, җирле үзидарә булыша,тирә-күршеләре ярдәм итә. Күрше хакы-тәңре хакы, диләр бит.Әнә шундый миһербанлы җаннар барында әбекәйләр картлар йорты тәрәзәләреннән карашларын еракларга төбәп сагыну-сагыштан саргаеп кипмәячәк.Бикүле авылында да караучысыз калган өлкәннәрне карап,тәрбияләп,җирле үзидарә Советы рәисе урынбасары Сания апа Батталова әйтмешли, «шәфкатьлелек үрнәге булып яшәүче» гаиләләр бар.Шуларның берсе Мөхәммәтҗановлар гаиләсе, Ислам абый белән Сания апа. Киң күңелле,ачык йөзле кешеләр. 1962 елда гаилә корып,биш бала үстереп,гомерләре буе туган авылларында эшләп яшәгәннәр. Хәзер лаеклы ялда.Балаларына оныкларын тәрбияләшәләр һәм... күршеләрендәге ятимә әбине карап торалар.Әти-әниләре -ике сугыш кичкән Кәрим бабай белән авылда тормышның ачысын-төчесен күргән Минбәян әбине кадер-хөрмәттә генә яшәтеп олылап соңгы юлга озаттылар.Үзен-үзе карый алмый башлагач, күршеләре Бәнат әби Сафиуллинаны үз тәрбияләренә алалар. Әбекәй,берничә еллар яшәп,үз балаларыдай кадерле күршеләренә хәер - догасын,бәхилләгән биреп якты дөнья белән хушлаша.Мусина Нургаян әби дә Ислам абый белән Сания апа гаиләсендә терәк,таяныч таба.Җеназасы алар нигезеннән чыга.Бүген Мөхәммәтҗановларда Сәрбиҗамал әби Исхакова яши.Нужаны,ялгызлыкны җитәрлек күргән әбинең күңеле тыныч,намазын укый, гамәлен кыла.Үзен тәрбияләүчеләргә теләкләр теле.Аны хөрмәт итәләр. «Әби утырмыйча бездә чәй янына утыру гадәте юк»,-ди Сания апа. Үзләре янында яшәүче уллары Илһам белән киленнәре Илсөярнең кечкенә кызлары да «Сәрбиҗамал әбети» дип гел әби тирәсендә бөтерелә. Димәк, өлкәннәрне хөрмәт итәргә кечкенәдән өйрәнеп үсә. Мөхәммәтҗановлар әнә шулай башкаларга игелек кылып мул,тату тормышта гомер итәләр. Бик күпләргә үрнәк алар.

Шөкер, мондый шәфкать-миһербанлы гаиләләр авылыбызда җитәрлек.Бикүленең үзендә тагын Минтаһир һәм Рәхимә Хәсәнҗановлар,Иске Авылда Равил һәм Затия Кәлимуллиннар,Кәкре Атаудан Зәкиулла һәм Фатыйма Садыйковлар, Дамир һәм Сәгадәт Алишевлар гаиләләре ялгыз әбиләрне карап,ярдәм итеп яшиләр. Үзләренең игелекле эш-гамәлләре белән алар күпләр өчен үрнәк.Ә изгелек җирдә ятмый ул.

**Җ.ШАКИРОВ.**

